Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «А.Х.Газизуллин исемендәге Югары Арбаш урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

**ФДББС кысаларында туган тел дәресләрендә комьютер технологиясен куллану**

Гибадуллина Ленара Гыйльметдин кызы

Туган тел һәм әдәбияты укытучысы

Хәзерге мәктәп яшь буынны конкурентлыкка, инновацион эшчәнлеккә, яңа төр вазифаларны үтәү юнәлешендә туган һәртөрле проблемаларны хәл итәргә; тәвәккәл, кыю, әмма дөрес карарлар кабул итә белергә өйрәтергә, балаларның интеллектуаль сәләтен үстерергә тиеш. Үз халкының тарихын, төбәген, нәселен яхшы белгән, милли җанлы, әхлаклы, иҗади фикерләүче, мәгълүмати чараларны оста куллана белүче шәхес тәрбияләү бурычы тора укытучы алдында. Бала шәхесен үстерү мәсьәләсенә төрле яклап якын килү сорала. Бу проблемаларны педагогик процессны оештыру технологиясен, методикасын яхшы белгән, укыту һәм тәрбия мәсьәләләрен тулырак чишү юлларын даими эзләгән очракта гына хәл итәргә мөмкин. Билгеле инде: һәр укытучы педагогик эштә югары нәтиҗәләргә ирешергә омтыла.Дәресләрдә һәм тәрбия сәгатьләрендә мәгълүмати технологияләр куллану укучыларга тирәнтен белем бирүгә ярдәм итә. Яңа технологияләр һәр укучыга шәхси якын килүне, дәрес материалын эчтәлеклерәк һәм кызыклырак итеп аңлатуны, укытуның нәтиҗәлеген күтәрүне күздә тота. Туган тел дәресләрендә комьютер технологиясен куллануның файдасы бар: лексик материалның дөрес язылышын, транскрипциясен, мәгънәсен , сурәтен бирергә мөмкин. Һәрбер рәсем яки язу экранда бирелә, ул яхшы күренә. Әдәби әсәрнең эчтәлеге буенча сурәтләр, өзекләр бирергә була. Сурәтләр төсле булгач, ул укучыларда кызыксыну тудыра.

Әдәбиятны укытуда мәгълүмати чаралардан файдалану бик кирәкле эш. Әдәби әсәрләрне өйрәнгәндә,электрон презентацияләр куллану бик отышлы. Электрон презентация – укытучы тарафыннан дәрестә куллана торган һәм аның аңлатма бирүен һәм өстәмәләр кертүен таләп итүче чара. Ул югары сыйныфларда үткәрелә торган лекция тибындагы дәрес структурасына да бик урынлы кереп урнаша. Яңа материалны аңлаткан чакта презентация бирелешенең мөмкинлекләре күп. Слайдларны күрсәтү тәртибе һәм төзү логикасы өйрәнелә торган материалның эчтәлегенә, аерым укучыларның аны үзләштерү үзенчәлекләренә , укытучы шәхесенә бәйле. Слайдларны текст

белән чуарламаска кирәк. Анда, башлыча, даталар, исем, термин, рәсем, схема, зур булмаган таблицалар, кыскача тезислар языла. Слайдның масштабы, төсе , фоны алдан уйланыла. Дәрес темасын аңлату- тулаем презентацияләнеп барылырга тиеш дигән сүз түгел. Аңлату барышында дәреслек белән бәйле эшләнә, тактага һәм дәресләргә дә языла, кагыйдәләр белән дә эш ителә. Бу очракта слайдларда бары тик терминнар яки кагыйдәләр генә языла. Дәрес материалын беренчел ныгытканда әңгәмә һәм тестлар белән эш итү уңайлы. Әгәр презентация дәреснең барлык этапларында кулланылса, аның аерым өлешләрен төрле фоннарда күрсәтү отышлырак. Тик шунысы бар: дәрестә слайдларны кирәгеннән артык күп кулланырга ярамый, шул вакытта бертөрле дә булмасын, шул чакта гына аларны куллану нәтиҗә бирәчәк.

Дәресләр үткәргәндә, презентация максатка ирешергә ярдәм итә, туган як темасын өйрәнгәндә,укытучы презентациясе дәрестә укучыга артык күп мәгълүмат бирми, сәламәтлегенә зыян китерми, дәрескә яраклаштырылып бирелә. Программа буенча белергә тиешле шигырьләрдән өзекләр, туган як күренешләре белән бирелә, укучының күз алдына туган якның, бөтен матурлыгы төрле төсләр белән үрелеп килеп баса. Шагыйрь иҗатына бирелгән бәя укучыларда тырышып хезмәт иткән кешенең тормышта үз урынын табуына ышандыра. Укучыларны үз төбәкләренең танылган шагыйрьләренең иҗаты белән таныштыру да әһәмияткә ия.

Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарури. Иң мөһиме шул: заманча технологияләрне куллану алынган мәгълүматның 85%ка якынын, ә традицион технологияләр – 40% белемне хәтердә озак сакларга ярдәм итә.